ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__3___ «__09_»_____01_____2017 ел

2017 елда районның гомуми белем бирү
учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш
белән тәэмин итүне оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 21 сентябрендә кабул ителгән “ 2017 нче елда айлык акчалата түләүләр һәм башка төрле түләүләр турындагы” 664 нче номерлы карары нигезендә, балаларнын сәламәтлеген һәм иминлеген тәэмин итү һәм 2017 елда районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. 2017 нче елның 9 нчы гыйнварыннан 31 нче декабренә кадәр Мамадыш муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә балаларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга.

Гомуми белем бирү учреждениеләрендә балаларны туклandыру өчен каралган чыгымнарны финанслау өчен район бюджетыннан акчаны түбәндәге суммадан чыгып исәпләргә:

-гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы 1 укучы өчен көненә 6 сум 80 тиен хисабыннан;

- 3 бала булган гаиләдә тәрбияләнүчеләр өчен көненә 1 укучыга өстәмә 5 сум хисабыннан;

- 4 һәм аннан күбрәк бала булган гаиләдә тәрбияләнүчеләр өчен 1 укучыга көненә өстәмә 15 сум;

- аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче, мәктәп яны интернатында яшәүче укучыларга 1 укучыга көненә 37 сум 66 тиен хисабыннан;

- озынайтылган көн төркемнәрендә шөгыльләнүче укучыларга – 8 сум 56 тиен хисабыннан;

- гомуми белем бирү учреждениеләренең бюджеттан тыш акчалары;

- әти- әниләрнең ( законлы вәкил) ирекле взнослары.

2. ТР Мамадыш муниципаль районы МБГБУ “Мамадыш шәһәре ак. К.Ә.Вәлиев исемендәге 2 нче номерлы лицейның” хоккей спорт классында, Мамадыш муниципаль районы МБГББ оешмасы “Мамадыш шәһәре 4 нче номерлы

мәктәбенең” кадет классында  белем алучы укучыларга 1 укучыга көненә өстәмә 12 сум 30 тиен хисабыннан акча бүлеп биререгә ;

3. Гамәлдә булган законнар нигезендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру өчен җаваплылыкны гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчеләренә йөкләргә.

4. Татарстан Республикасының кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнары буенча территориаль идарәсенә (Маснавиева М.Х.) гомуми белем бирү учреждениеләренә тәэмин итүчеләр тарафыннан китерерлгән, учреждение ашханәсендә әзерләнгән ризыкларның сыйфатын даими тикшереп торуны( лаборатор контрольне дә кертеп)  контрольгә алуны тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Сергеев А.М.) гомуми белем бирү учреждениеләрендә балаларны кайнар аш белән тәэмин итү очен каралган акчаларның, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ “Мәгариф бүлегенең” нормативлар билгеләнгән  сметасына нигезләнеп, үз вакытында күчүен тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ “Мәгариф бүлегенә” (Габдрахманов И.Н.) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы (Сергеев А.М) белән берлектә 2018 елда гомуми белеем бирү учреждениеләрендә сыйфатлы тукландыруны оештыру максатыннан материаль – техник базаларны ныгыту, ашханәләрне җиһазлау буенча булган тәкъдимнәрен Мамадыш муниципаль район Советына кертергә; сыйфатлы туклануны оештыру өчен бүленгән акчаларның максатчан тотылуын тәэмин итәргә;  кече фермаларда, мәктәп яны участокларында җитештерелгән продукция хисабына менюны тулыландыру буенча эшне көчәйтергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П.Смирновка йөкләргә.

Җитәкче                                                                                    И.Э.Фаттахов